СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 24 » март 2023 ел** **№ 200**

**2023 елга Арча муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 22 июлендәге159-ФЗ номерлы Федераль законнар, Арча район Советының 2008 елның 27 декабрендәге 224 номерлы карары белән расланган «Арча муниципаль районында муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмә» (14.10.2011 №74, 17.05.2012 №137, 28.05.2015 №342, 12.07.2016 №61, 10.11.2016 №87, 10.11.2017 №152, 19.09.2019 №275 үзгәрешләр белән) нигезендә, муниципаль мөлкәт белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан, Арча район Советы карар бирде:

1. 2023 елга Арча муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы сайтында (www.arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г.Нуриев

Арча район Советының
______________ ел, №__
карары белән расланды

**2023 елга Арча муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)**

I бүлек. Мөлкәтне хосусыйлаштыру өлкәсендә төп юнәлешләр

2023 елга Арча муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) гамәлгә ашыруның төп максаты (алга таба - хосусыйлаштыру программасы) муниципаль мөлкәт белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру.

2023 елда муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 21.12.2001 №178-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендә булган яки муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендага алынган күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 22.07.2008 №159-ФЗ Федераль законнар, Арча район Советының 2008 елның 27 декабрендәге 224 номерлы карары белән расланган «Арча муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» нигезләмә (14.10.2011 N 74, 17.05.2012 №137, 28.05.2015 №342, 12.07.2016 №61, 10.11.2016 №87, 10.11.2017 №52, 19.09.2019 №275 үзгәрешләр белән) һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының һәм «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең үзара хезмәттәшлеге турында 2017 елның 22 июнендәге Килешү нигезендә гамәлгә ашырылачак.

1. 2023 елда мөлкәтне хосусыйлаштыру бурычлары.

Чираттагы елда мөлкәтне хосусыйлаштыру бурычлары:

- район икътисадында структур үзгәртеп коруларны дәвам итү;
- муниципаль милек структурасын оптимальләштерү;
- икътисадның реаль секторына инвестицияләр җәлеп итүне стимуллаштыру;
- муниципаль милек объектларын хосусыйлаштыруның максималь бюджет нәтиҗәлелеген тәэмин итү;
- кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү.

2. Хосусыйлаштыруның район икътисадында, шул исәптән икътисадның аерым тармакларында (идарә өлкәләрендә) структур үзгәрешләргә йогынтысы фаразы.

2023 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган муниципаль мөлкәт объектлары исемлегенә районның муниципаль милкендәге объектлар кертелде.

2023 елда муниципаль унитар предприятиеләрне, муниципаль милектәге акционер җәмгыятьләрнең акцияләрен хосусыйлаштыру планлаштырылмый.

Гомумән алганда, 2023 елга Арча районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планында (программасында) күрсәтелгән мөлкәт объектларын хосусыйлаштыру район икътисадында, шул исәптән икътисадның аерым тармакларында (идарә итү өлкәсендә) структур үзгәрешләргә йогынты ясамаячак.

3. Арча муниципаль районы бюджетына муниципаль мөлкәтне сатудан кергән керем фаразы.

Арча районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) нигезендә 2023 елга 8 күчемсез объектны хосусыйлаштыру күздә тотыла.

Арча муниципаль районы бюджетына күчемсез һәм күчемле муниципаль мөлкәт объектларын хосусыйлаштырудан планлаштырылган керемнәр кимендә 1 500,00 мең сум тәшкил итәчәк.

**III бүлек. 2023 елда планлаштырыла торган хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт исемлеге**

| № | Мөлкәтнең исеме һәм урнашкан урыны | Характеристикасы | Фаразланган хосусыйлаштыруны үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | Арча муниципаль районы, Үрнәк ав., Дуслык ур., 7 йорт адресы буенча урнашкан балалар бакчасы бинасы һәм җир кишәрлеге | 208,6 кв.м. мәйданлы, бер катлы, агач | ел дәвамында |
| 2. | Венета ав., Үзәк ур., 13 йорт адресы буенча урнашкан административ бина һәм җир кишәрлеге | 57,5 кв. м мәйданлы, бер катлы | ел дәвамында |
| 3. | Адресы: Шурабаш ав., Гагарин ур., 17 йорт адресы буенча урнашкан административ бина һәм җир кишәрлеге | 230,5 кв. м мәйданлы, бер катлы | ел дәвамында |
| 4. | Сикертән ав., Мәктәп ур., 79 йорт адресы буенча урнашкан котельный бинасы, административ бина һәм җир кишәрлеге | Административ бина - 120,1 кв.м мәйданлы, бер катлы; котельный бинасы - 16.1 кв.м. мәйданлы, бер катлы | ел дәвамында |
| 5. | Арча шәһәре, Совет мәйданы, 10 йорт (объект мәдәни мирас объектлары реестрына кертелгән) адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге булган торак булмаган бина (РФ Үзәк банкы бинасы) | 461,7 кв.м. мәйданлы, өч катлы, шул исәптән 1 җир асты каты | ел дәвамында |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6. | Кушлавыч ав., Тукай ур., 62 йорт адресы буенча урнашкан китапханә бинасы һәм җир кишәрлеге | 85,1 кв. м мәйданлы, бер катлы | ел дәвамында |
| 7. | Арча муниципаль районы, Үрнәк ав., Шәрык ур., 11 йорт адресы буенча урнашкан балалар бакчасы бинасы һәм җир кишәрлеге | 188,1 кв.м. мәйданлы, бер катлы, агач | ел дәвамында |
| 8. | CHEVROLET NIVA 212300-55 маркалы автомобиль | 2014 елда чыгарылган, ачык-көмеш металлик төсендә | ел дәвамында |
| 9. | CHEVROLET NIVA 212300-55 маркалы автомобиль | 2014 елда чыгарылган, караңгы-соры металл төсендә | ел дәвамында |
| 10. | CHEVROLET NIVA 212300-55 маркалы автомобиль | 2015 елда чыгарылган, ачык-көмеш металлик төсендә | ел дәвамында |
| 11. | CHEVROLET NIVA 212300-55 маркалы автомобиль | 2015 елда чыгарылган, көмеш төсендә | ел дәвамында |
| 12. | CHEVROLET NIVA 212300-55 маркалы автомобиль | 2018 елда чыгарылган, караңгы-соры металл төсендә | ел дәвамында |
| 13. | Lada 211440 маркалы автомобиль | 2011 елда чыгарылган, соры-яшел металлик төсендә | ел дәвамында |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 14. | ЗИЛ 130 | 1992 елда чыгарылган | ел дәвамында |
| 15. | FIAT DUCATO | 2010 елда чыгарылган, сары төстә | ел дәвамында |
| 16. | ПАЗ 423470 | 2011 елда чыгарылган, сары төстә | ел дәвамында |
| 17. | ПАЗ 423470 | 2011 елда чыгарылган, сары төстә | ел дәвамында |
| 18. | ПАЗ 32053-70 | 2008 елда чыгарылган, сары төстә | ел дәвамында |
| 19. | ПАЗ 32053-70 | 2011 елда чыгарылган, сары төстә | ел дәвамында |
| 20. | ПАЗ 32053-70 | 2011 елда чыгарылган, сары төстә | ел дәвамында |
| 21. | Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Сөрде авылы, Совет урамы, 8 йорт адресы буенча урнашкан бина, торак йорт һәм җир кишәрлеге | 22,6 кв.м мәйданлы, бер катлы, кадастр номеры 16:09:210401:174 | ел дәвамында |
| 22. | Арча муниципаль районы, Хәсәншәех авылы, Комсомол урамы, 2 йорт адресы буенча урнашкан балалар бакчасы бинасы һәм җир кишәрлеге | 223,7 кв. м мәйданлы, бер катлы | ел дәвамында |